РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Исполнительный комитет
Тойкинского сельского поселения
Азнакаевского
муниципального района

ул. Джалиля, д.19, с.Тойкино, 423302,
тел./факс (885592)45-0-89
E-mail: Toy.Azn@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Азнакай муниципаль районы
Туйкә авыл җирлеге
башкарма комитеты

Җәлил ур.,19 йорт, Азнакай районы,
Туйкә авылы, 423302
тел./факс (885592)45-0-89
E-mail: Toy .Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**от «07»апрель 2023 ел.** **№ 4**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Туйкә авыл җирлеге башкарма комитетының 2017 елның 17 ноябрендәге 24 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Туйкә авыл җирлеге территориясен планлаштыру документларын әзерләү тәртибен раслау турында» карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Туйкә авыл җирлеге территориясен планлаштыру документларын әзерләү тәртибенә үзгәреш кертү турында (2018 елның 07 маендагы 10 номерлы, 2019 елның 05 апрелендәге 24 номерлы, 2019 елның 10ктябрендәге 35 номерлы карарлар редакциясендә)

«Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында 2022 елның 29 декабрендәге 612-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә һәм «Россия Федерациясендә тимер юл транспорты турында» Федераль законның 16 статьяның 2 пунктының икенче абзацы үз көчен югалтуын тану хакында» Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Туйкә авыл җирлегенең башкарма комитеты **карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Туйкә авыл җирлеге башкарма комитетының 2017 елның 17 ноябрендәге 24 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Туйкә авыл җирлеге территориясен планлаштыру документларын әзерләү тәртибен раслау турында» карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Туйкә авыл җирлеге территориясен планлаштыру документларын әзерләү тәртибенә үзгәреш кертү турында (2018 елның 07 маендагы 10 номерлы, 2019 елның 05 апрелендәге 24 номерлы, 2019 елның 10ктябрендәге 35 номерлы карарлар редакциясендә ) 2.14 пунктында «бер ай һәм өч айдан артык» сүзләрен «ундүрт көн һәм утыз көннән артык» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда веб-адрес буенча: http://pravo. tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында веб-адрес буенча: http//aznakayevo. tatarstan.ru. урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Башлык Р.Р.Закирова